СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.04.2016 Алабуга шәһәре № 59

Алабуга муниципаль районы Советының
«Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы
Иҗтимагый совет турында» 2
008 елның 30 апрелендәге 172 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

РФ Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы, «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек һәм мәгарифне саклау өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру чаралары турында» 2013 елның 24 октябрендәге 793 номерлы карары нигезендә һәм Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү максатыннан, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2008 елның 30 апрелендәге 172 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.8 пунктында 2 санын 4 санына алмаштырырга;

1.2. 5.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү җаваплы секретарьга йөкләнә, ул Совет әгъзалары арасыннан сайлана»

1.3. 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренең сыйфатына җәмәгать контролен көчәйтү, тиешле өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессионализм принципларын үстерү»;

1.4. 2.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«башкарма орган эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын арттыру;

- мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек һәм белем бирү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәя бирү».

1.5. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 2.4 пункты белән тулыландырырга:

«2.4. Иҗтимагый советының максатлары һәм бурычлары аның эш нәтиҗәләренә карап үзгәрергә һәм тулыланырга мөмкин, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьне дә исәпкә алып».

1.6 2.3. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Иҗтимагый совет үзенә йөкләнгән бурычлар чикләрендә сыйфатны бәйсез бәяләүне гамәлгә ашырган очракта:

- сыйфатка бәйсез бәя бирү үткәрелүче оешмаларның (учреждениеләрнең) исемлеген билгели;

- югарыда күрсәтелгән оешмалар (алга таба - оператор) тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турында мәгълүматны җыючы, гомумиләштерүче һәм анализлаучы оешма өчен техник бирем эшләү өчен тәкъдимнәр формалаштыра, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар турындагы документация проектларын, шулай ук оператор белән башкарма орган төзи торган муниципаль контрактлар проектларын караууда катнаша;

- кирәк булганда оешмалар хезмәт күрсәтүләренең сыйфатын бәяләү критерийларын билгели (федераль законнарда билгеләнгән гомуми критерийларга өстәмә рәвештә);

- җәмәгатьчелек фикерен ачыклау, гомумиләштерү һәм анализлау, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар рейтингларын төзү эшен оештыра, шул исәптән, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, профессиональ берләшмәләр һәм башка экспертлар тарафыннан формалаштырыла;

- оешмаларның сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм тиешле эшчәнлеген яхшырту турындагы тәкъдимнәрне башкарма органга юллый».

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль үсеш мәсьәләләре буенчадаими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе Г.Е. Емельянов